| | |
|---|---|
| Совет Абалачевского сельского поселения Менделеевского муниципального района Республики Татарстан | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Советы |

Карар

2022 елның 18 апреленнән №69

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган махсуслаштырылган торак фондының хезмәт торак урыннарын бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Абалач авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының» Абалач авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге милкендә булган махсуслаштырылган торак фондының хезмәт торак урыннарын бирү тәртибе турындагы нигезләмәне әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында https://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Абалач авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга: https://mendeleevsk.tatarstan.ru/

3. Менделеевск муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына хезмәт торак урыннары бирү регламентын әзерләргә һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Абалач авыл җирлеге советында раслауга бер ай вакыт эчендә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегенең торак комиссиясенә йөкләргә.

Абалач авыл җирлеге Советы рәисе Р.Н. Сиражетдинов